**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 19 июлендәге 3046 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2022 елның 18 гыйнварындагы 100 номерлы «Учреждениеләргә үзәкләштерелгән бухгалтерлык, хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыра торган муниципаль учреждениеләрнең, оештыру һәм финанс эшчәнлеген тәэмин итә торган хезмәтләрнең хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында»**

2024 елның 1 июленнән учреждениеләргә үзәкләштерелгән бухгалтерлык, хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтүне тормышка ашыручы муниципаль учреждениеләр, социаль-культура өлкәсендәге учреждениеләрнең, оештыру һәм финанс эшчәнлеген тәэмин итүче хезмәтләрнең хезмәткәрләренең эш хакын арттыру максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 18 гыйнварындагы 100 номерлы «Учреждениеләргә үзәкләштерелгән бухгалтерлык, хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтүне тормышка ашыручы муниципаль учреждениеләр, оештыру һәм финанс эшчәнлеген тәэмин итүче хезмәтләрнең хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 номерлы кушымтадагы «Хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибе» дигән II бүлекнең 1 таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1 таблица

**Оештыру һәм финанс эшчәнлеген**
**тәэмин итүче хезмәтләрнең җитәкчеләре, белгечләре**
**һәм хезмәткәрләре вазифалары атамалары һәм вазифаи окладлары исемлеге**

| № т/б | Вазифа атамасы | Вазифаи оклад, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Бухгалтер | 24800 |
| 2 | Документлар белән эшләүче белгеч | 24800 |
| 3 | Инженер | 24800 |

| №<br>т/б | Вазифа атамасы | Вазифаи оклад, сумнарда |
|---|---|---|
| 4 | Җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча белгеч | 24800 |
| 5 | Икътисадчы | 24800 |
| 6 | Әйдәүче бухгалтер | 26500 |
| 7 | Әйдәүче бухгалтер-ревизор | 26500 |
| 8 | Документлар белән эшләүче әйдәүче белгеч | 26500 |
| 9 | Әйдәүче инженер | 26500 |
| 10 | Әйдәүче инженер-программачы | 26500 |
| 11 | Әйдәүче белгеч | 26500 |
| 12 | Кадрлар буенча әйдәүче белгеч | 26500 |
| 13 | Җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча әйдәүче белгеч | 26500 |
| 14 | Әйдәүче икътисадчы | 26500 |
| 15 | Әйдәүче эксперт | 26500 |
| 16 | Әйдәүче юрисконсульт | 26500 |
| 17 | Сатып алулар буенча өлкән белгеч | 26500 |
| 18 | Сектор мөдире | 30500 |
| 19 | Төркем башлыгы урынбасары/бүлек башлыгы урынбасары | 30500 |
| 20 | Төркем башлыгы/бүлек башлыгы | 34793 |
| 21 | Баш бухгалтер урынбасары | 34793 |
| 22 | Баш бухгалтер | 40300» |

1.2. 1 номерлы кушымтадагы «Хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибе» дигән II бүлекнең 2 таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2 таблица

**Учреждениеләргә үзәкләштерелгән бухгалтерлык һәм хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтә торган муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре вазифалары атамалары һәм вазифаи окладлары исемлеге**

| №<br>т/б | Вазифа атамасы | Вазифаи оклад, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Администратор | 24800 |
| 2 | Архивариус | 24800 |
| 3 | Бухгалтер | 24800 |
| 4 | Инженер | 24800 |
| 5 | Әйдәүчебухгалтер | 26500 |
| 6 | Документлар белән эшләүче әйдәүче белгеч | 26500 |
| 7 | Әйдәүче инженер | 26500 |
| 8 | Әйдәүче инженер-программачы/ әйдәүче белгеч | 26500 |
| 9 | Әйдәүче инженер-смета төзүче | 26500 |
| 10 | Сатып алулар буенча әйдәүче белгеч | 26500 |
| 11 | Кадрлар буенча әйдәүче белгеч | 26500 |
| 12 | Әйдәүче икътисадчы | 26500 |
| 13 | Әйдәүче эксперт | 26500 |
| 14 | Әйдәүче юрисконсульт/ әйдәүче юрисконсульт-эксперт | 26500 |
| 15 | Бүлек башлыгы урынбасары | 28115 |

| № т/б | Вазифа атамасы | Вазифаи оклад, сумнарда |
|---|---|---|
| 16 | Сектор мөдире/баш белгеч | 29175 |
| 17 | Учреждениенең сатып алулар буенча бүлекчәсе (контракт хезмәте) җитәкчесе/хезмәт башлыгы | 30500 |
| 18 | Бүлек башлыгы | 30500 |
| 19 | Участок башлыгы /хезмәт башлыгы | 30500 |
| 20 | Баш инженер | 35060 |
| 21 | Директор урынбасары | 35060 |
| 22 | Директорның беренче урынбасары | 35060 |
| 23 | Директор/идарә итүче директор | 42825» |

1.3. 1 номерлы кушымтаның «Хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибе» дигән II бүлегендәге 2 таблицадан соң түбәндәге эчтәлекле 2.2(1) һәм 2.2(2) пунктлар өстәргә:

«2.2(1). «Казан шәһәренең муниципаль оешмаларына бухгалтерлык хезмәте күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе идарәче директорына һәм «Казан шәһәренең социаль өлкә объектларына хезмәт күрсәтү һәм карап тоту департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе директорына вазифаи окладка карата 1,82 күләмендә персональ арттыру коэффициентын билгеләргә;

2.2(2). Окладка арттыру коэффициентын куллану яңа оклад барлыкка китерә һәм компенсация, стимуллаштыру һәм социаль характерындагы түләүләр исәпләгәндә исәпкә алына»;

1.4. 2 номерлы кушымтаның «Хезмәт хакының айлык ставкасы, аны билгеләү тәртибе һәм шартлары» дигән II бүлегендәге 1 таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1 таблица

**Эшчеләрнең хезмәт хакының айлык ставкалары**

| № т/б | Эшче һөнәрләрнең аталышы | Хезмәт хакының айлык ставкасы, сумнарда | Казан шәһәрендә үзәкләштерелгән бухгалтерлык һәм хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтә торган учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче автомобиль йөртүчеләр өчен хезмәт хакының айлык ставкасына арттыру коэффициенты |
|---|---|---|---|
| 1 | Җыештыручы | 19242 | - |
| 2 | Каравылчы | 19242 | - |
| 3 | Автомобиль йөртүче | 19242 | 1,377 |
| 4 | Вахтер | 19242 | - |
| 5 | Хуҗалык өчен җаваплы хезмәткәр | 19242 | - |
| 6 | Биналарга хезмәт күрсәтүче эшче | 19242 | - |

| № т/б | Эшче һөнәрләрнең аталышы | Хезмәт хакының айлык ставкасы, сумнарда | Казан шәһәрендә үзәкләштерелгән бухгалтерлык һәм хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтә торган учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче автомобиль йөртүчеләр өчен хезмәт хакының айлык ставкасына арттыру коэффициенты |
|---|---|---|---|
| 7 | Урам себерүче | 19242 | -» |

1.5. 2 номерлы кушымтаның «Хезмәт хакының айлык ставкасы, аны билгеләү тәртибе һәм шартлары» дигән II бүлегендәге 1 таблицадан соң түбәндәге эчтәлекле 2.2(1) пункт өстәргә:

«2.2(1). Хезмәт хакының айлык ставкасына арттыру коэффициентын куллану хезмәт хакының яңа айлык ставкасын барлыкка китерә һәм компенсация, стимуллаштыру һәм социаль характерындагы түләүләр исәпләгәндә исәпкә алына»;

1.6. 2 номерлы кушымтаның «Стимуллаштыру характерындагы түләүләр, аларны билгеләү тәртибе һәм шартлары» дигән IV бүлегенең 4.2 пунктында «оклад» сүзен «хезмәт хакының айлык ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 2 номерлы кушымтаның «Стимуллаштыру характерындагы түләүләр, аларны билгеләү тәртибе һәм шартлары» дигән IV бүлегенең 4.3 пунктында «оклад» сүзен «хезмәт хакының айлык ставкасы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итүне бюджет классификациясенең тиешле бүлекләре буенча билгеләнгән тәртиптә каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә һәм 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**